Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының
« Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Иж-Бәйки торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**12.11.2025** **№ 1**

Гамәлдәге законнар нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына таянып, 2025 елның 12 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта "Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бәйки торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекләләр ) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналар, ирләре яки хатыннары), I төркем инвалидлардан, өлкән яшьтәге ялгыз гражданнардан (80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәкләрдән), көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясенә хәрби хезмәткә чакырылган һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш), 2026 елда үзара салым акчасын 500 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (чүп үләннәрен чабу; юлларны кардан чистарту, тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, трактор өчен запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм торак пунктны төзекләндерү буенча башка чыгымнар);

2) су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; сантехник һәм чыгым материаллары, насослар сатып алу, суүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм Иж-Бәйки торак пунктын су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар;

3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзекләндерү, карап тоту ( юлларга түшәү өчен вак таш сатып алу һәм эшләү; автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар).

башкаруга юнәлтүгә, кулланyга ризамы?" дигән сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

« РИЗА» «КАРШЫ»

Беркетмә нигезендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында:

Гражданнар җыенында  сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 143 катнашучы кертелде. Гражданнар җыенында тавыш бирүдә  катнашучылар саны 73 кеше, бу 51% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенының 70 катнашучысы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен – 3 катнашучы.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены  карар кылды :

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бәйки  торак пунктында гражданнар җыенын узган дип,  гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Әгерҗе муниципаль районы « Иж-Бубый авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иж-Бәйки  торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекле хезмәткәрләр ) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналары, ире яки хатыны), Ітөркем инвалидлардан, өлкән яшьтәге ялгыз  гражданнардан (80 яшькә җиткәннәрдән), көндезге формада укучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм ректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш) 2026 елда үзара салым акчаларын 500 сум күләмендә кертергә.

3.Алынган акчаларны, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга  юнәлтергә:

1) Торак пункт территориясен төзекләндерү  (чүп үләннәрен чабу; юлларны кардан чистарту, тракторны карап тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү, трактор өчен запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу  һәм торак пунктны төзекләндерү буенча башка чыгымнар);

2) Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су  башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; сантехник һәм чыгым материаллары, насослар сатып алу, сүүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм Иж-Бәйки торак пунктын су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар;

3) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзекләндерү, карап тоту ( юлларга түшәү өчен вак таш  сатып алу һәм эшләү;  автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар).

4) Иж-Бәйки торак пункты  зиратының коймаларын  төзекләндерү (койма өчен материаллар сатып алу һәм коймаларны кору, Иж-Бәйки торак пунктын традицион  зират төзекләндерү буенча башка чыгымнар);

4. Карарны Иж-Бубый  авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы сайтында (https://agryz.tatarstan.ru), «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең

Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Ваhапов